**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ОКТЯБРЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МУСЛЮМОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОКТЯБРЬ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

*423984, РТ, Муслюмовский район, с.Октябрь, ул.Молодежная, д.3а,*
Okt.Mus@tatar.ru *тел. 8(8-5556) 3-51-26*
ИНН 1629004040, КПП 162901001, ОГРН 1021687005346, ОКАТО 92242860001

*Октябрь авылы* *«_14_»___03___2019 ел.*

**Карар № 2**

**2019 елгы язгы ташу чорына Мөслим муниципаль районы Октябрь авыл җирлеге халкын һәм территориясен саклау чаралары турында.**

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Октябрь авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 7 маддәсе нигезендә 2019 елгы язгы ташу чорында халыкны, хуҗалык һәм торак объектларын, юлларны һәм күперләрне саклауны кисәтү максатларында Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Октябрь авыл җирлеге Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Октябрь авыл җирлеге территориясендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерүне һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча комиссия төзү.
2. Октябрь авыл җирлеге территориясендә 4 кешедән торган гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерүне һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясен төзергә һәм 2019 елгы язгы ташу чорында Октябрь авыл җирлеге халкын һәм территориясен саклау буенча чаралар планын расларга.
3. Октябрь авыл җирлеге гадәттән тыш хәлләрне кисәтү, бетерүне һәм икътисад объектларының янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясенә тәкъдим итәргә:
   - Октябрь авыл җирлегенең гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм янгын куркынычсызлыгы, язгы ташуга каршы комиссия утырышларында икътисад объектларының куркынычсызлыгы, язгы ташу суларының авариясез үтүен тәэмин итү мәсьәләләрен карарга;
   - язгы ташу күренешләре аркасында килеп чыккан гадәттән тыш хәлләргә игътибар бирү һәм авария-торгызу эшләрен үткәрүгә җәлеп ителә торган көч һәм чаралар группировкасын ачыклау. Көч һәм чаралар турында мәгълүматлар җыю һәм гомумиләштерү, аларның гамәлләрен тикшереп тору;
   - елга һәм буаларда, саркофагларсыз үләт базлары янында су дәрәҗәсен тәүлек буе күзәтү өчен вакытлыча постлар оештырырга; - язгы ташуга каршы чаралар оештыруны тәэмин итү;
   - язгы ташу белән бәйле гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен халыкка җиткерүне тәэмин итәргә;
   - халыкны һәм территорияләрне язгы ташуның тискәре нәтиҗәләреннән саклау буенча чараларның үткәрелүен контрольдә тотуны тәэмин итәргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Октябрь авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Ханнанов И.М.

Мөслим муниципаль районы
Октябрь авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесенең
«14» март, 2019 ел,
2нче санлы Карарына
1нче кушымта

**Октябрь авыл җирлеге буенча**
**гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерүне тәэмин итү комиссиясе.**

**Әндереш авылындагы гидротехник корылма буенча:**

1. Хайретдинов Фәнис Әглямович - ОАО Алгинская ПМК "Мелиорация" прорабы

2.Хазиев Марсель Мирзамухаметович;

3. Нуретдинов Илнур Мирзанурович.

**Бәкәбез авылындагы гидротехник корылма буенча:**

1. Хайретдинов Фәнис Әглямович - ОАО Алгинская ПМК "Мелиорация" прорабы

2. Ризванов Фидаес Миргалимович;

3. Хамматов Василь Мирзамухаметович

Октябрь авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Ханнанов И.М.